| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>ШАЛТИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ШАЛТЫ<br>АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

29 марта 2019 г. с.Шалты № 85

Баулы муниципаль районы
Шалты авыл җирлеге Советының
2018 елның 18 маенда № 53 карары
белән расланган Баулы муниципаль
районы Шалты авыл җирлеген шәһәр
төзелеше проектлаштыруның җирле
нормативларына үзгәрешләр кертү турында
(06.08.2018 № 61, 19.11.2018
№ 75 үзгәрешләре белән)

Россия Федерациясенең шәһәр төзелеше кодексы нигезендә 29.12.2004 ел, № 190-ФЗ (23.04.2018 редакциясендә) (кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр 2018 елның 28 июнендә үз көченә керде), Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлеге Советының 2018 елның 18 маенда № 53 карары белән расланган Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлеген шәһәр төзелеше проектлаштыруның җирле нормативларына (06.08.2018 № 61, 19.11.2018 № 75 үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

4.1.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Торак пунктлар чикләрендә билгеләнелә торган территориаль зоналар составына авыл хуҗалыгы кулланылышы зоналары (шул исәптән авыл хуҗалыгы җирләре зоналары), шулай ук авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге объектлар белән шөгыльләнүче һәм авыл хуҗалыгын алып бару, бакчачылык һәм яшелчәчелек, авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге объектларны үстерү өчен билгеләнгән зоналар да кертелә ала.»;

2.2.2 пунктында 2 таблицадан соң бара торган абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Торак зоналарда аерым төзелгән яисә төзелгән социаль һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектлар, сәламәтлек саклау объектлары, мәктәпкәчә, башлангыч гомуми һәм урта гомуми белем бирү объектлары, дини биналар, автомобиль транспорты стоянкалары, гаражлар, гражданнар яшәүгә бәйле һәм әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясамый торган объектлар урнаштыру рөхсәт ителә. Торак зоналар составына шулай ук бакчачылык алып бару өчен билгеләнгән территорияләр дә кертелергә мөмкин.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.

Шалты авыл җирлеге
Башлыгы, Совет рәисе Фаткуллин З.Х.